Р. Ф. Исламов

# ТУКАЙНЫ ӨЙРӘНҮДӘ ЯҢА ЧЫГАНАКЛАР

***Фәнни мәкаләләр***

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2016

УДК 821.512.145
ББК 83.3(2Рос=Тат)1
И80

**Исламов, Р. Ф.**

И80 Тукайны өйрәнүдә яңа чыганаклар : фәнни мәкаләләр / Р. Ф. Исламов. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2016. – 191 б. : рәс. б-н.

ISBN 978-5-298-03111-0

Филология фәннәре докторы Рәмил Исламовның бу китабында татар халык шагыйре Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗат эшчәнлегенә бәйле яңа материаллар нигезендә язылган мәкаләләре туплап бирелде.

Китап татар әдәбияты галимнәренә, укытучыларга, аспирантларга һәм студентларга тәкъдим ителә.

УДК 821.512.145
ББК 83.3(2Рос=Тат)1

ISBN 978-5-298-03111-0

© Татарстан китап нәшрияты, 2016
© Исламов Р. Ф. 2016

*Тукайны өйрәнүгә зур өлеш керткән галимнәр Сәгыйть Исәнбаев һәм Рашат Гайнановның якты рухларына багышлыйм.*

# КЕРЕШ

Татар халык шагыйре Габдулла Тукайның (1886–1913) тормыш юлын һәм иҗат мирасын максатчан өйрәнү юнәлешендә соңгы вакытларда алып барган эзләнүләрем үзенең бәрәкәтле нәтиҗәләре белән сөендерә.

Укучыга тәкъдим ителгән бу җыентыкны чит илләрдә, аерым алганда Кытай Халык Республикасының Шенҗаң-Уйгур автономияле районы көндәлек матбугатындагы шагыйрьгә багышланган мәкаләләр; әдипнең хәзерге вакытка кадәр ачыкланмый килгән һәм башка фотолары; 1910 елның 15 апрелендә «Шәрекъ клубы»нда аның тарафыннан укылган «Халык әдәбияты» дигән лекциягә керү билеты һәм ул ядкярнең иясе; әдипнең 1912 елгы яз-җәй айларында Казан – Уфа – Петербург – Троицк – Казан маршруты белән йөреп кайткан тарихи сәфәрләре; вафатыннан соң аны соңгы юлга озатканда катнашкан имамнар һәм кайбер шәхесләр; искә алу кичәләре һәм шундый мәдәни чараларның чит илләрдә басылып чыккан мәҗмугасы; Г. Тукайның иҗат үзенчәлекләре; аның тормыш юлы һәм әдәби эшчәнлеген өйрәнгән аерым галимнәр; кайбер дөреслеккә туры килмәгән язмалар; истәлекләр сөйләп калдырган кешеләрнең күмәк фотосы турында яңа материаллар тәшкил итә.

Китапта урын алган материаллар үз вакытында «Мәдәни җомга», «Кызыл таң», «Мәгърифәт» газеталарында, «Научный Татарстан», «Тулпар» журналларында, Г. Тукай юбилейларына багышланган фәнни җыентыкларда дөнья күреп, укучыларда зур кызыксыну уятты.

Әлеге һәм киләчәктә табылуы ихтимал булган башка материаллар Г. Тукай турында алга таба дөнья күрәчәк яңадан-яңа хезмәтләр әзерләгәндә кыйммәтле чыганак булыр дигән теләктә калабыз.

## Тукай текстологы – Рашат Гайнанов

XX йөз башы татар әдәбиятын барлау һәм аны җыйнап-туплап, фәнни нигездә өйрәнү юнәлешендә башкарылган шактый хезмәтләр бар. Алар арасында киң эрудицияле әдәбият белгече, текстолог Рашат Рәшит улы Гайнановның (1925–1990) фидакяр эшчәнлеге аерым урын били.

Әлеге могтәбәр зат үз вакытында төрле матбугат битләрендә әдәбият, тел мәсьәләләренә караган, күп кенә әдипләрнең, хосусән Габдулла Тукай (1886–1913), Фатих Әмирхан (1886–1926), Һади Такташ (1901–1931), Галимҗан Ибраһимов (1887–1938), Фатих Кәрим (1909–1945), Муса Җәлил (1906–1944), Гадел Кутуй (1903–1945), Нәкый Исәнбәт (1899–1992), Гыйффәт Туташ (Заһидә Бурнашева; 1895–1977), Заһирә Байчурина (1890–1977), Гали Хуҗи (1912–1966), Гамил Афзал (1921–2003) һ. б. ның тормыш юлы, иҗаты турында, шулай ук башка актуаль темаларга публицистик, тәнкыйди, гыйльми характерда мәкаләләр язган.

Ул 1958 елда ук күренекле тарихчы һәм язучы Газиз Гобәйдуллинның (1887–1937) хикәяләр җыентыгын төзеп бастыра һәм анда хәзерге укучыга беренче тапкыр әлеге галим турында саллы кереш мәкалә, аның хезмәтләренең библиографиясен бирә.

Актив җәмәгать эшлеклесе һәм шагыйрә Заһирә Байчуринаның «Ана сүзе» дип исемләнгән шигырьләр мәҗмугасына (1959) кереш сүз яза һәм махсус мөхәррире була, Т. Фаикъ төзеп нәшер иткән Нәҗип Думави (1883–1933) шигырьләре һәм поэмалары китабының (1960) шулай ук махсус мөхәррире була, искәрмәләрен яза.

Галим 1975–1977 еллар аралыгында Г. Тукайның дүрттомлык, ә 1985–1986 елларда биштомлык «Әсәрләр» җыентыгын төзеп чыгара. Биштомлыкка текстларны әзерләүдә Лена Гайнанова да катнашкан.

Рашат Гайнанов әдип һәм дәүләт эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның сигез томлы «Әсәрләр»енең беренче томында (1974) текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләгән; икенче, өченче, дүртенче томнарында (1975, 1976) шул ук эшне Афзал Шамов (1901–1990) белән берлектә башкарган. Бишенче – публицистика томын төзүче, искәрмәләр һәм аңлатмаларны әзерләүчеләр – Мансур Хәсәнов (1930–2010) белән Рашат Гайнанов. Алтынчы – шулай ук публицистика томын төзүче, искәрмәләр һәм аңлатмалар әзерләүче – Рашат ага.

Ул Һади Такташ өчтомлыгының өченче томына (1983) фәнни мөхәррирләрнең берсе була.

«Һади Такташ – яңа тормыш җырчысы» дигән фәнни конференция материаллары белән бер китапта чыккан шагыйрьнең библиографиясен редакцияләү, «Татар әдәбияты тарихы»ның өченче томына хронология төзү кебек эшләр дә – Р. Гайнанов хезмәте.

«Библиографик белешмә» өчен сигез йөзгә якын язучы турында алфавит тәртибендә аның тарафыннан башкарылган этрафлы мәгълүмат үзе генә дә әдәбият гыйлеменең күркәм битләреннән саналыр.

Әлеге шәрәфле мәҗлес Г. Тукайның 110 ел тулу уңае белән үткәрелүне истә тотып, шагыйрьнең иҗади мирасын өйрәнүдә биниһая көч куйган Рашат аганың якты истәлеген янә бер тапкыр яд итеп, без үзебезнең зур булмаган чыгышыбызда галимнең бу өлкәгә караган хезмәтләрендәге кайбер моментларга гына тукталып үтүне кирәк санадык.

Р. Гайнанов тарафыннан төзелеп дөнья күргән дүрттомлыктан аңлашылганча, анда алдагы басмаларда җибәрелгән шактый гына төгәлсезлекләр, җитешсезлекләр төзәтелгән. Җыентыкка галим эзләнүләренең уңышы булган, Г. Тукайныкы икәнлеге фәнни нигездә исбат ителгән утызлап шигырь һәм егермегә якын мәкалә өстәлгән, ә биштомлыкта исә аларның саны йөз егерме биш.

Шагыйрьнең архивта сакланып калган кайбер язмаларына, замандашларының истәлекләренә, шул чор вакытлы матбугат һәм башка чыганакларга таянып, текстолог томнарда әсәрләрнең язылу һәм басылу хронология тәртибен якынча утыз процентка дөресли, үзгәртә.

Тынгысыз галим гомере буе тикшеренүләре нәтиҗәсендә Тукай язышкан газета-журнал битләреннән шагыйрьнең утызлап псевдонимын ачыклауга ирешә. Мәсәлән, Уральскида Камил Мотыйгый (1883–1941) тарафыннан нәшер ителгән «Уклар»да, «Фикер»дә генә дә Г. Тукай үзенең әсәрләренә атаклы «Шүрәле», электәнрәк билгеле булган «Кырмыска», «Һөдһөд», «Тәртә башы» дигән яшерен имзалар куйган. Ул анда янә «Хәсрәт», «Шәкерт угы», «Җен», «Сөңге», «Хәйләсез», «Чапансыз», «Мылтык», «Мәхүб прахуты кантуршигы», «Догачы», «Адвокат», «Мәкәрҗәдә булучы», «Каза», «Бән» кебекләрен дә кулланган. Текстологның күзәтүенчә, аларның кайберләре соңрак башка басмаларда да очрый.

Г. Тукай әсәрләрен шулай күптөрле псевдоним астында бастыру сәбәпләренә килгәндә исә, галим раславынча, алар шагыйрьнең ифрат күп эшләве, аның тыйнаклыгы һәм шул ук вакытта мондый алымның сатира-юмор жанрында язучылар өчен хас табигыйлек белән аңлатыла.